Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында

БӘЯЛӘМӘ

Иске Урыссу авылы 27.05.2024 ел

Үткәрү көне һәм вакыты, гамави тыңлауларны үткәрү урыны: 2024 елның 25 мае 15 сәгать 00 минутта мәскәү вакыты белән түбәндәге адрес буенча: 423960, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Урыссу авыл җирлеге, Иске Урыссу авылы, Советская ур., 45а йорты, авыл мәдәният йорты бинасы.

Гавами тыңлаулар предметы: Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын карау.

Гавами тыңлауларны уздыру өчен нигез: Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча басылып чыккан һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырылган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгының 2024 елның 25 апрелендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында»гы 28 санлы карары.

Гавами тыңлауларны уздыру инициаторы: Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы Шәфигуллин А.Ә.

2024 елның 26 апреленнән 2024 елның 25 маена кадәр халык алдында тыңлаулар үткәрү барышында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкыннан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркемгә кисәтүләр яки тәкъдимнәр килмәде.

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча тәкъдим ителгән материалларны, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча 2024 елның 25 маендагы ачык тыңлаулар беркетмәсен карап чыкканнан соң, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең

Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү процедурасы үтәлгән һәм Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы таләпләренә туры килә дип саный.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлауларны узган дип таный.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты материалларны хупларга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге Генераль планы проектын алга таба раслау мәсьәләсен карарга тәкъдим итә.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

Кушымта:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча 2024 елның 25 маендагы ачык тыңлаулар протоколы.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина